ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Красавин ур., 40 нчы йорт, Яр Буе Морквашы авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

14.11.2020 № 4

На №_____________ от______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Лесные Моркваши авылында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясы нигезендә, 2020нче елның 14нче ноябрендә узган «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Лесные Моркваши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча: - Лесные Моркваши авылында адреслы табличкалар алу, дигән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 55 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 29 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда 28 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 1 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Лесные Моркваши авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Лесные Моркваши авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегенең Лесные Моркваши авылында 2021нче елда 500 сум күләмендә үзара салым җыюга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча : - Лесные Моркваши авылында адреслы табличкалар алу, дигән җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез риза булырсызмы, дигән мәсьәлә буенча граждannar җыены карарын танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районының Яр Морквашы авыл җирлегенең Лесные Морквашы авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын теркәүгә җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И. Х. Гаязов